ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕЧЕКУРСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

*422483, село Нижнее Чекурское*
*телефон: 33-1-34*

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТҮБӘН ЧӘКЕ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

*422483, Түбән Чәке авылы*
*телефон: 33-1-34*

с.Нижнее Чекурское

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27 гыйнвар 2021 ел № 4

Агач һәм куаклар кисүгә, кронлаштыруга яки утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлеге башкарма комитетының 2019 ел 26 августында 19 номерлы карары белән расланган (№20, 12.09.2019 ел редакциясендә) "Агач һәм куаклар кисүгә, кронлаштыруга яки утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына" түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**2.6 пунктка түбәндәге эчтәлекле пунктча** өстәргә:

«2) үтәү вакыты Россия Федерациясе законнары нигезендә (авария хәлләренә бәйле очраклардан тыш) килгән очракта, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар булмау турында белешмә.»;

**2.8 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:**

«5) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булу.»;

**3.4.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:**

«законнарны бозган өчен салымнар, җыемнар, пенялар һәм штрафлар түләү буенча бурычлар булу (булмау) турында белешмәләр.».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә һәм Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлегенең рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Түбән Чәке авыл җирлеге башлыгы: О.Б.Албутов